**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2023 елның 29 марты** **40-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаруны йөкләү турында

А. Г. Карсаловның Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаруы мөмкин булмау сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 12 өлешенә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 9 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставының 46 статьясының 4 пункты белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе билгеләнгәнче (конкурс нәтиҗәләре буенча) 2023 елның 30 мартыннан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Нурмөхәммәтов Азат Әнәс улына йөкләргә.

2.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Башлык - муниципаль район**
**Совет рәисе** **И.Ф. Зарипов**